# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Майна авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Чуваш Майнасы торак пунктында 2025 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

**2024 елның 17 октябрендәге 2 номерлы**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елгы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Майна авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Чуваш Майнасы торак пунктында гражданнар җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Майна авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Чуваш Майнасы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, көндез укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә чакырылган,МХО да катнашучы гражданнардан тыш, 2025 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;
- торак пункт территориясен төзекләндерү;
- ремонт, коймалар кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү;
- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү.
- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыклары төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия ясалган очракта Майна авыл җирлеге башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

3. Әлеге карарны Майна авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http://alekseevskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr:/ / pravo. tatarstan .ru)бастырып чыгарырга .

**Гражданнар җыенында рәислек итүче,**
**Алексеевск муниципаль районы Майна**
**авыл җирлеге башлыгы** **Я.Д.Иванов**